# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА ҮРГӘАГАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
# КАРАРЫ

2020 елның 10 июне 10№

Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлеге Советының 2018 елның 14 декабрендәге 29 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне раслау хакында"гы карарына үзгәрешләр кертү турында

2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы Федераль закон һәм 2013 елның 25 июнендәге 50-ЗРТ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы 2020 елның 7 маендагы 20-ЗРТ номерлы «Аерым категорияле вазыйфаи затларның коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашу тәртибен камилләштерү өлешендә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы Татарстан Республикасы законы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлеге Советының 2018 елның 14 декабрендәге 29 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне раслау хакында» гы карарына (2020 елның 12 февралендәге 4 номерлы редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

-4 пунктны (2020 елның 12 февралендәге 4 номерлы редакциясендә) (4.Карар имза салынган көннән үз көченә керә) төшереп калдырырга.

- Түбәндәге эчтәлекле 7.1 бүлек өстәргә:

**"7.1. Муниципаль хезмәткәрнең коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуы**

1. Муниципаль хезмәткәрнең коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасын сайлап алучы орган, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты белән идарә итүдә, съездда (конференциядә) яисә башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашудан тыш) (алга таба әлеге статьяда - коммерцияле булмаган оешма) катнашуы әлеге статьяда билгеләнгән тәртиптә алынган яллаучы вәкиле рөхсәте белән гамәлгә ашырыла.

2. Муниципаль хезмәткәрнең коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуы мәнфәгатьләр конфликтына яисә мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлеген китермәскә тиеш.

3. Коммерцияле булмаган оешма идарәсендә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт бирү турында муниципаль хезмәткәрнең гаризасы (алга таба әлеге статьяда - гариза) әлеге Карарның 1 нче кушымтасы нигезендә муниципаль хезмәткәрне яллаучы вәкиле исеменә язма рәвештә төзелә.

4. Гариза җирле үзидарә органының кадрлар хезмәтенә (кадрлар эшен башкару өчен җаваплы вазыйфаи затына), муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратына (алга таба әлеге статьяда - кадрлар хезмәте) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә планлаштырылган катнашу башланганчыга кадәр тапшырыла.

-түбәндәге эчтәлекле 1 нче кушымта өстәргә:

1 нче кушымта

(кемгә) ____________________________________________

(муниципаль хезмәткәрнең яллаучы вәкиленең

____________________________________________

вазыйфасы фамилиясе, инициаллары)

(кемнән)____________________________________________

(муниципаль хезмәткәрнең вазыйфасы,

____________________________________________

фамилиясе, инициаллары)

Коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен рөхсәт турында
ГАРИЗА

2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында"гы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктының "б" пунктчасы һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 16.1 статьясы нигезендә Сездән коммерцияле булмаган оешма идарәдә түләүсез нигездә катнашырга рөхсәт итүегезне сорыйм.

____________________________________________________________________________

(коммерцияле булмаган оешманың исеме, урнашу урыны һәм адресы,

____________________________________________________________________________

коммерцияле булмаган оешманың эшчәнлек төрләре, нинди сыйфатта идарә итү(идарә итүдә катнашу) планлаштырыла)

Коммерцияле булмаган оешма белән идарә итү (идарәдә катнашу) хезмәттән буш вакытта гамәлгә ашырылачак һәм үз артыннан мәнфәгатьләр каршылыгы яки муниципаль хезмәтнең билгән вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлегенә китермәячәк.

_____________ _______________________________
(имза) (фамилия, инициаллар)

20____ елның "______"_______________

Гаризалар теркәү журналында теркәлү номеры_______

Гаризаны теркәү датасы 20______ елның "______"__________________

_____________ __________________________________________________
(имза) (гаризаны теркәгән затның вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары)";

- түбәндәге эчтәлекле 2 нче кушымта өстәргә:

2 нче кушымта

Коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу өчен рөхсәт алу турында гаризаларны теркәү журналы

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| т/бN (гаризаның теркәү номеры) | Гаризаны теркәү датасы | Гаризаның кыскача эчтәлеге | Гариза биргән затның инициаллары, фамилиясе, вазыйфасы | Гариза кабул иткән затның инициаллары, фамилиясе, вазыйфасы | Гаризаның күчермәсен алу турында билге ("Күчермәсен алдым", гариза тапшырган затның имзасы) | Яллаучының вәкиле тарафыннан кабул ителгән карар турында билге | Гаризаны тапшырган зат турында, яллаучы вәкиленең карар күчермәсе ("Күчермәсен алдым", гариза тапшырган затның имзасы) яисә тапшыру турында хәбәрнамә белән яллаучы вәкиле карарын почта элемтәсе аша җибәрү турында (карар җибәргән затның адресы, имзасы) билге |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8". |

24 статьяга түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

"10. "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 40 статьясындагы 7 бүлекнең 2 пунктындагы "б" пунктчасында һәм 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы "Коррупциягә каршы тору турында" Федераль законның 12.1 статьясындагы 3.5 бүлекнең 2 пунктында каралган очракларда муниципаль вазыйфа биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы зат, коммерцияле булмаган оешмалар белән, әлеге Карарның 1 нче кушымтасы нигезендә, Татарстан Республикасы Президентына алдан хәбәрнамә юллап, түләүсез идарә итүдә катнашырга хокуклы.";

7 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

"5. Әлеге карарның 17, 18 һәм 32 статьяларында каралган түләтүләр муниципаль хезмәткәрләргә коррупцияле хокук бозу турында мәгълүмат кергән көннән алып, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча хезмәткә сәләтсезлек чорын, аның отпускта булуын исәпкә алмыйча, алты айдан да соңга калмыйча һәм коррупция буенча хокук бозу кылынган көннән алып өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән вакытка җинаять эше буенча тикшерү вакыты кертелми.";

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Яңа Үргәагар авыл җирлегенең мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе,
Яңа Үргәагар авыл җирлеге Башлыгы: Рәхимҗанов Ә.Ә.